СОВЕТ
НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

03 июнь 2024 ел

№162

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип танунының өстәмә нигезләрен билгеләү турында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Норлат авыл җирлеге Советы

карар итте:

1. 1 нче кушымта нигезендә җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танунының өстәмә нигезләрен билгеләргә.
2. Норлат авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 июнендәге 119 номерлы «Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танунының өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.

Норлат авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе

И.М.Саттаров

Норлат авыл җирлеге Советының 2024 елның 03 июнендәге 162 номерлы карарына №1 нче кушымта

Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танунын өстәмә нигезләре.

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түләтү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч өметсез дип таныла:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танунын өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) 1 пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) 1 пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) 1 пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булуы турында белешмәсе.